КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 сентябрь г.Казань № 731

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләп чыгарыла торган хезмәткәр-ләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 19 октябрь, 870 нче; 2012 ел, 6 ноябрь, 966 нчы; 2013 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1104 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 762 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1123 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1029 нчы; 2022 ел, 13 сентябрь, 987 нче; 2024 ел, 6 май, 300 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карарга 1 нчы кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 14 июнь, 477 нче
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 5 сентябрь, 731 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең
тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлар)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 21 200 |
| 2 | 1,0114 | 21 442 |
| 3 | 1,0233 | 21 694 |
| 4 | 1,0346 | 21 934 |
| 5 | 1,0473 | 22 203 |
| 6 | 1,0595 | 22 461 |
| 7 | 1,0728 | 22 743 |
| 8 | 1,0855 | 23 013 |
| 9 | 1,0983 | 23 284 |
| 10 | 1,1119 | 23 572 |
| 11 | 1,1251 | 23 852 |
| 12 | 1,1393 | 24 153 |
| 13 | 1,1535 | 24 454 |
| 14 | 1,1675 | 24 751 |
| 15 | 1,1823 | 25 065 |
| 16 | 1,1973 | 25 383 |
| 17 | 1,2124 | 25 703 |
| 18 | 1,2280 | 26 034 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.

______________________________